РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

улица К.Маркса, дом 46,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

К.Маркс урамы, 46 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел.(84342) 5-13-38, тел/факс 5-13-38, E-mail: chistay@tatar.ru

***Постановление*** ***Карар***

07.04.2023 Чистай шәһәре №46

«Чистай шәһәр Башкарма комитетының
«Муниципаль ихтыяҗлар өчен
күпфатирлы торак йортларда җир кишәрлекләрен
һәм торак урыннарны тартып алу турында»гы
2023 елның 25 гыйнварындагы
5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында”

Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 53.2 статьясы, 56,3 статьясы һәм 56,6 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Авария хәлендәге йортлар исемлеген раслау турында»гы 2011 елның 28 октябрендәге 124 номерлы карары, «Күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында»гы 2017 елның 5 июлендәге 130 номерлы карарлары нигезендә, Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Торак урынның милекчесе үзгәрү сәбәпле, карарның 2 нче пунктын төшереп калдырып, 1, 2 нче кушымталарына үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карар чыгарылган көннән алып 10 (ун) көн эчендә:
- аны массакүләм мәгълүмат чараларында, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы”нда бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;
- 1 нче һәм 2 нче кушымталарда күрсәтелгән торак урыннар һәм җир кишәрлекләре милекчеләренә әлеге карарның күчермәсен һәм күчемсез мөлкәтне тартып алу турында килешү проектын җибәрергә;
- әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте идарәсенең Чистай бүлегенә җибәрергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов